**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

25.10.2022 980-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 6 ноябрендәге 794-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 6 ноябрендәге 794-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) рәсми сайт – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүматны үз эченә алган сайт, аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә электрон адресы хокукы Министрлыкка караган домен исемен үз эченә ала.»;

2.11 пунктның 6 пунктчасының икенче абзацында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу боерык 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков